РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«26» декабря 2024г. г. Альметьевск № 337

Әлмәт муниципаль районы Советының 2021 елның 15 ноябрендәге 93 номерлы «Әлмәт муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Һава кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 8 августындагы 289-ФЗ номерлы Федераль закон, шулай ук норматив-хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү кысаларында хәвеф-хәтәр индикаторларын актуальләштерү турында Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы хаты (2024 елның 24 сентябрендәге 19357 номерлы) нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Советының 2021 елның 15 ноябрендәге 93 номерлы «Әлмәт муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында Нигезләмәне раслау хакында» карарына (Әлмәт муниципаль районы Советының 2021 елның 16 декабрендәге 113 номерлы, 2022 елның 13 июлендәге 153 номерлы, 2023 елның 6 июлендәге 232 номерлы, 2023 елның 2 ноябрендәге 258 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарга 1 нче кушымтаның 4 бүлегендәге 4.6 пунктының 4.6.3 пунктчасында «66 статьясындагы 12 өлешендә» сүзләрен «66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләрендә» сүзләренә алмаштырырга;

карарга 1 нче кушымтаның 4 бүлегендәге 4.7 пунктының 4.7.8 пунктчасында «66 статьясындагы 12 өлешендә» сүзләрен «66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләрендә» сүзләренә алмаштырырга;

карарга 1 нче кушымтаның 4 бүлегендәге 4.9 пунктының 4.9.4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.9.4. Урынга барып тикшерү нәтиҗәләре буенча «Россия Федерациясе Һава кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 8 августындагы 289-ФЗ номерлы Федераль законның 90 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктында каралган карар кабул ителергә тиеш түгел;

карарга 2 нче кушымтага түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3. Автомобиль юлларын ремонтлау һәм карап тоту эшләрен башкаруга контрактны үтәү шартларын бер календарь ел дәвамында үтәмәү фактлары (нормаль параметрларның 10% тан артыгракка кимүе).

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Туманова Г.П.).

Муниципаль район
Башлыгы урынбасары

«СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА»

А.А. Зимин